**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР №29**

**III чакырылыш XXXII утырыш Урыссу ш.т.б. 2020 елның 26 мае**

**«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениясе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында»гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 17 апрелендәге Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру хакында» 272 санлы Указы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2020 елның 24 апрелендәге Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» "ПУ-250 санлы Указы, 2020 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 18 санлы карары белән кабул ителгән Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы к а р а р и т т е:

1. 2015 елның 27 февралендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Ютазы муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2 санлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 3 абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» электрон челтәр массакүләм мәгълүмат чарасында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://yutazy.ru (ЭЛ № ФС 77 - 47613, 07.12.2011) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча теркәргә: http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында

Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының авыл җирлекләре советлары белән законлылык, регламент һәм үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Башлыгы урынбсары** **З.М. Аглиева**